СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**19 октябрь 2020 ел** **№ 4**

**Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Урта Курса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Урта Курса авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Урта Курса авылында Урта Курса авылы, Яшьләр урамы, 13 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2020 елның 11 ноябрена 10 сәгать 00 минутта халык җыенының билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Урта Курса авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-Урта Курса авылы зираты коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляциялэнгэн чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру, Яшьләр урамы буенча 5 линия сузу
- Урта Курса авылында автомобиль юлларын вак таш җәеп тигезләү;
- "Изгеләр чишмәсе" коймасын ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

3. Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Урта Курса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Урта Курса авылы, Тукай урамы, 21 йорт йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Вафина